КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 сентябрь г.Казань № 986

2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турында, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты хакында

2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турындагы, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразы, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты хакындагы докладларны тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрларын хупларга.

2. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проектын исәпкә алырга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына 2022 елның 22 сентябренә кадәр «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын, әлеге закон проекты белән бер үк вакытта

тапшырыла торган документларны һәм материалларны теркәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә карауга кертергә.

4. Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына 2022 елның 22 сентябренә кадәр «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә карауга кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин